СОВЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

______________ с. Введенская Слобода ______________

19.12.2018 237

Социаль әһәмияткә ия объектларның, кешеләр күпләп була торган урыннарда иминлеге һәм «Яңа ел-2019» бәйрәменә әзерлек һәм аны уздыру чорында гражданнарның иҗтимагый иминлеген тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында

Яңа ел бәйрәм чараларының, гражданнарның тормышы һәм сәламәтлеге, физик һәм юридик затларның, дәүләт һәм муниципаль мөлкәтнең янгынга каршы куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында “Янгын куркынычсызлыгы турында” 1994елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы, “Янгын куркынычсызлыгы турында” 1993елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2018 елның 20 декабреннән 2018 елның 10 гыйнварына кадәр Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим урнаштырырга.

2. Махсус янгынга каршы режим гамәлдә булган чорда торак-коммуналь хуҗалык объектлары, авыл хуҗалыгы объектлары, кешеләр күпләп була торган объектлар чикләреннән 50 метр ераклыкта урнашкан территорияләрдә 1-3 классны куркыныч пиротехник эшләнмәләрдән (бенгаль утларыннан, мамык кисәкләреннән тыш) файдалануны тыю билгеләргә.

3. Введенский Бистәсе авыл җирлеге халкы тарафыннан Зөя елгасының яр буе территориясен пиротехник эшләнмәләр куллану урыны итеп билгеләргә.

4. Карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы

Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д.В. Морозов